СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**28 октябрь 2024 ел** Болгар ш. **№ 42-6**

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы милкендәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган арендалана торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен 5 (биш ел) һәм күчемле мөлкәт өчен 3 (өч ел) тәшкил итә.

2. Сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләү тәртибен (бер мәртәбә яисә өлешләп түләү), шулай ук арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яисә урта эшкуарлык субъектына әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә өлешләп түләү срогын сайлау хокукы бирелә.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм httr://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми порталындарәсми рәвештә халыкка җиткерергә

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны ТР Спас муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Спас муниципаль районы башлыгы,
Советы рәисе Ф.В. Мөхәммәтов